РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет
Елантовского сельского поселения
Нижнекамского муниципального района

423597, Нижнекамский район,
с. Елантово,ул. Нагорная,1г

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Түбән Кама муниципаль районы
Елантау авыл жирлеге
Советы

423597, Түбән Кама районы,
Елантау авылыНагорная урамы, 1г

тел. /факс (8555) 33-30-42, электронный адрес: Elant.Nk@tatar.ru, сайт: www.elantovskoe-sp.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

21.02.2020ел № 54-109

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге Советының 2012 елның 07 декабрендәге 25-79номерлы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 48 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге Уставының 62 статьясы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен Түбән Кама муниципаль районы Советына тапшыру турында килешүләрне раслау хакында» 2018 елның 17 маендагы 37 номерлы карарына таянып, Түбән Кама муниципаль районы Советының «Түбән Кама муниципаль районы Советының 2012 елның 20 декабрендә кабул ителгән 68 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләрененңкоррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 февралендәге 18 номерлы карарын игътибарга алып, Елантау авыл җирлеге Советы карар бирә:

1. Елантау авыл җирлеге Советының 2012 елның 7 декабрендә кабул ителгән 25-79 номерлы «Түбән Кама муниципаль районы Елантау авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Елантау авыл җирлеге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.Г. Гайнутдинов